**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.06.2015 № 425

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2015 елның 13 июлендә теркәлде, № 2789

**“Бөек Ватан сугышы ветераны” таныклыгын (таныклыкның дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының ““Бөек Ватан сугышы ветераны” таныклыгын (таныклыкның дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 05.07. 2012 ел, № 514 боерыгы белән расланган административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында**

“Бөек Ватан сугышы ветераны” таныклыгын (таныклыкның дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатыннан боерык бирәм:

Кушымта итеп бирелүче яңа редакциядә бәян итеп, “Бөек Ватан сугышы ветераны” таныклыгын (таныклыкның дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының ““Бөек Ватан сугышы ветераны” таныклыгын (таныклыкның дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 05.07. 2012 ел, № 514 боерыгы белән расланган административ регламентына үзгәрешләр кертергә.

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 22.06.2015 ел, № 425 боерыгына кушымта

**“Бөек Ватан сугышы ветераны” таныклыгын (таныклыкның дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. “Бөек Ватан сугышы ветераны” таныклыгын (таныклыкның дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең бу административ регламенты (алга таба – Регламент) “Бөек Ватан сугышы ветераны” таныклыгын (таныклыкның дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алучылар:

1.2.1. “Бөек Ватан сугышы ветераны” таныклыгын (таныклыкның дубликатын) бирү буенча:

1) “Блокададагы Ленинградта яшәгән кешегә” билгесе белән бүләкләнгән, аларны пенсия белән тәэмин итү Россия Федерациясе Пенсия фонды органнары тарафыннан башкарыла торган затлар;

2) 1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәрге чорда тылда кимендә алты ай (СССРның вакытлыча оккупацияләнгән территорияләрендә эшләү чорыннан гайре) эшләгән затлар; Бөек Ватан сугышы чорындагы фидакарь хезмәтләре өчен СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләнгән, аларны пенсия белән тәэмин итү Россия Федерациясе Пенсия фонды органнары тарафыннан башкарыла торган затлар;

1.2.2. “Бөек Ватан сугышы ветераны” таныклыгының дубликатын бирү буенча:

1) Бөек Ватан сугышында катнашкан, аларны пенсия белән тәэмин итү Россия Федерациясе Пенсия фонды органнары тарафыннан башкарыла торган затлар:

а) Гражданнар сугышы чорында, Бөек Ватан сугышы чорында яки Ватанны яклау буенча башка сугышчан операцияләр чорында хәрби хезмәт үткән яисә хәрәкәттәге армия составына керүче хәрби частьларда, штабларда һәм учреждениеләрдә вакытлыча булган хәрби хезмәткәрләр (хәрби частьларда тәрбияләнгәннәрне һәм юнгаларны да кертеп), шул исәптән запаска (отставкага) чыгарылганнары да, шулай ук партизаннар һәм Гражданнар сугышы чорында яки Бөек Ватан сугышы чорында СССРның вакытлыча оккупацияләнгән территорияләрендә эшләгән яшерен оешмалар әгъзалары;

б) хәрби хезмәткәрләр, шул исәптән запаска (отставкага) чыгарылганнары да, эчке эшләр органнарының һәм дәүләт иминлеге органнарының рядовойлар һәм башлыклар составында булып, хәрәкәттәге армия хәрби частьларының хәрби хезмәткәрләре өчен гамәлгә кертелгән ташламалы шартларда пенсия билгеләү өчен, Бөек Ватан сугышы чорында аларны саклауда катнашу – тиешле еллар хезмәт итү булып санала торган шәһәрләрдә хезмәт иткән затлары;

в) армия һәм флотның, эчке эшләр гаскәрләре һәм органнарының, дәүләт иминлеге органнарының үз ирке белән ялланган составында булып, Бөек Ватан сугышы чорында хәрәкәттәге армия составына керүче хәрби частьларда, штабларда һәм учреждениеләрдә штаттагы вазыйфалар биләгән, яисә хәрәкәттәге армия хәрби частьларының хәрби хезмәткәрләре өчен гамәлгә кертелгән ташламалы шартларда пенсия билгеләү өчен, әлеге чорда аларны саклауда катнашу – тиешле еллар хезмәт итү булып санала торган шәһәрләрдә булган затлар;

г) Бөек Ватан сугышы чорында хәрәкәттәге армия составына керүче хәрби частьларда, дошман тылында яки башка дәүләтләр территорияләрендә махсус заданиеләр үтәгән разведка, контрразведка хезмәткәрләре;

д) предприятиеләр һәм хәрби объектлар, наркоматлар, ведомстволарның Бөек Ватан сугышы чорында Кызыл Армия сафларында торучы һәм хәрәкәттәге фронтларның тыл белән янәшә чикләре яки хәрәкәттәге флотның операцияләр башкару зоналары тирәсендә армия һәм флот мәнфәгатьләрендә бурычлар үтәүче затлар хәленә күчерелгән хезмәткәрләре, шулай ук Бөек Ватан сугышы чорында хәрәкәттәге армиягә командировкага җибәрелгән учреждениеләр һәм оешмалар (шул исәптән мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре һәм оешмалары) хезмәткәрләре, үзәк газеталар, журналлар, ТАСС, Совинформбюро һәм радио корреспондентлары, Документаль фильмнар үзәк студиясе (кинохроника) кинооператорлары;

е) хәрби хезмәткәрләр, шул исәптән запаска (отставкага) чыгарылганнары да, эчке эшләр органнарының һәм дәүләт иминлеге органнарының рядовойлар һәм башлыклар составында булган затлары, Бөек Ватан сугышы чорында дошман десантлары белән көрәш буенча сугышчан операцияләрдә һәм хәрәкәттәге армия составына керүче хәрби частьлар белән бергә сугыш хәрәкәтләрендә катнашкан, шулай ук 1944 елның 1 гыйнварыннан 1951 елның 31 декабренә кадәрге чорда Украина, Белоруссия, Литва, Латвия һәм Эстония территорияләрендә националистлар подпольесын бетерү буенча сугышчан операцияләрдә катнашкан истребительләр батальоннарының, взводларының һәм халыкны яклау отрядларының сугышчылары һәм командирлар составы; хәрәкәттәге флот составына кермәүче подразделениеләрдә Бөек Ватан сугышы чорында сугышчан траллау операцияләрендә катнашкан, шулай ук 1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәрге чорда СССР Осоавиахимы оешмалары һәм җирле хакимият органнары тарафыннан территорияләрне һәм объектларны миналардан арындыруга, боеприпаслар һәм хәрби техниканы җыюга җәлеп ителгән затлар;

ж) Бөек Ватан сугышы чорында башка дәүләтләр территорияләрендә партизан отрядлары, яшерен төркемнәр, башка төрле антифашист формированиеләр составында фашистлар Германиясенә һәм аның союзникларына каршы сугыш хәрәкәтләрендә катнашкан затлар;

з) хәрәкәттәге армия составына кермәүче хәрби частьларда, учреждениеләрдә, хәрби уку йортларында 1941 елның 22 июненнән 1945 елның 3 сентябренә кадәрге чорда кимендә алты ай хәрби хезмәт үткән хәрби хезмәткәрләр, шул исәптән запаска (отставкага) чыгарылганнары да; әлеге чорда

СССР орденнары яки медальләре белән бүләкләнгән хәрби хезмәткәрләр;

и) “Ленинград оборонасы өчен” медале белән бүләкләнгән затлар; 1941 – 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы чорындагы сугыш хәрәкәтләренә бәйле яралану, контузия яки имгәнү нәтиҗәсендә бала чакта инвалид калганнар;

2) Бөек Ватан сугышы чорында һава һөҗүменә каршы оборона, һава һөҗүменә каршы җирле оборона объектларында, хәрәкәттәге фронтларның тыл янәшәсендәге чикләре тирәсендә, хәрәкәттәге флотларның операцияләр зоналарында, тимер һәм автомобиль юлларының фронт белән янәшә участокларында саклану корылмалары, хәрби-диңгез базалары, аэродромнар һәм башка төрле хәрби объектлар төзүдә эшләгән затлар.

1.2.3. 1.2.1 һәм 1.2.2 пунктларда күрсәтелгән, “Бөек Ватан сугышы ветераны” таныклыгы РФ Хөкүмәтенең № 284 карары үз көченә кергәнгә кадәр бирелгән, яисә 1992 елның 1 гыйнварына кадәр расланган үрнәктәге таныклыклар бирелгән гражданнар исәбенә керүче затлар.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә мөрәҗәгать итүчеләр (алга таба – гариза бирүче) булып бу Регламентның 1.2.1, 1.2.2 һәм 1.2.3 пунктларында күрсәтелгән дәүләт хезмәте алучылар яки аларның законлы вәкилләре (законнар белән күздә тотылган очракларда), яисә закон белән билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә эш итүгә дәүләт хезмәте алучылар тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар тора.

1.4. Дәүләт хезмәте “Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан, дәүләт хезмәте алучының яшәү урынында Татарстан Республикасы муниципаль районында яки шәһәр округында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Социаль яклау идарәсе (бүлеге) (алга таба – Идарә (бүлек)) йөзендә күрсәтелә.

1.4.1. Идарәнең (бүлекнең) урнашу урыны, белешмәләр алу өчен телефоннары, электрон почта адреслары турындагы мәгълүмат бу Регламентка белешмә-кушымтада китерелгән.

Идарәнең (бүлекнең) эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән тыш көн саен. Идарәнең (бүлекнең) эш сәгатьләре эчке тәртип кагыйдәләре нигезендә билгеләнә.

1.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) халыкны кабул итү бүлмәсендә, Идарәләрдә (бүлекләрдә) урнашкан, дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматтан торган, дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмат стендларына урнаштырыла торган мәгълүмат дәүләт хезмәте турында бу Регламентның 1.1, 1.4.1, 1.5, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган белешмәләрне үз эченә ала.

2) “Интернет” челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында: http://www.mtsz.tatarstan.ru;

Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм

порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Идарәгә (бүлеккә), Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Идарәгә (бүлеккә), Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә хәл ителә:

"Ветераннар турында" 12 гыйнвар, 1995 ел, № 5-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 5-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 3, 168 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Электрон имза турында" 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 63-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Персональ мәгълүматлар турында" 27 июль, 2006 ел, № 152-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31 (1 өлеш), 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында" 7 май, 2012 ел, № 601 Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба – № 601 Указ) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 07.05.2012, № 19, 2338 ст.);

КПСС ҮК һәм СССР Министрлар Советының "Бөек Ватан сугышында катнашып, хәрби хезмәткәрләр һәм партизаннар исәбенә керүчеләр өчен КПСС ҮК һәм СССР Министрлар Советының 1978 елның 10 ноябрендәге № 907 карары белән билгеләнгән ташламаларның хәрәкәттәге армиянең үз ирке белән ялланган составына кагылуы турында" 1981 елның 27 февралендәге № 220 карары (алга таба – КПСС ҮК һәм СССР Министрлар Советының № 220 карары) (СССРның СП, 1981, № 12, 70 ст.);

Бөек Ватан сугышы ветераны таныклыгын тутыру, бирү һәм исәпкә алу тәртибе хакында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Бөек Ватан сугышы ветераны таныклыклары турында" 05.10.1999 ел, № 1122 карары белән расланган инструкция (алга таба – № 1122 Инструкция) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1999, № 42, 5038 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Бөек Ватан сугышы ветераннарының, сугыш хәрәкәтләре ветераннарының, гражданнарның башка категорияләренең "Ветераннар турында" Федераль закон белән билгеләнгән хокукларын һәм ташламаларын тормышка ашыру тәртибе һәм шартлары турында Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль үсеш министрлыгының "Бөек Ватан сугышы ветераннарының, сугыш хәрәкәтләре ветераннарының, гражданнарның башка категорияләренең "Ветераннар турында" Федераль закон белән билгеләнгән хокукларын һәм ташламаларын тормышка ашыру тәртибе һәм шартлары турындагы инструкцияне раслау хакында" 11.10.2000 ел, № 69 карары белән расланган инструкция (алга таба – № 69 Инструкция) (Башкарма хакимиятнең федераль органнары норматив актлары

бюллетене, 2000, № 48, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 5 октябрь, 1999 ел, № 1122 карарына үзгәрешләр кертү турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 31 март, 2009 ел, № 284 карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең № 284 карары) (Российская газета, № 63, 10.04.2009);

“Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре” 15.08.2007, № 388 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 388 ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 05.09.2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – № 880 Тәртип) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.6. Бу Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның мәгълүмат керткәндә нигез булып торган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хата).

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документларны кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләргә консультацияләр үткәрү “тәрәзә”се;

Бу Регламентта “дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза” (алга таба – гариза) төшенчәсе 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктында күздә тотылган дәүләт хезмәтен күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатьне аңлата. Гаризаның тәкъдим ителә торган формасы бу Регламентка 1 нче кушымтада китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка таләпләрнең эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү атамасы | “Бөек Ватан сугышы ветераны” таныклыгын (таныклыкның дубликатын) (алга таба – таныклык (таныклык дубликаты)) бирү | № 5-ФЗ Федераль законның 28 ст.;<br>№ 1122 Инструкциянең 1п., 8 п. |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче орган (учреждение) атамасы | Дәүләт хезмәте алучының яшәү урынында Татарстан Республикасы муниципаль районында яки шәһәр округында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Социаль яклау идарәсе (бүлеге) (алга таба – Идарә (бүлек)) йөзендә – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) | № 1122 Инструкция |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып | Таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү гариза һәм бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән башлап 9 эш көне эчендә башкарыла.<br>Таныклык бирү гариза бирүче таныклык (таныклык дубликатын) алырга килгән көнне башкарыла. | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә мөрәҗәгать итүче тапшырырга тиешле кирәкле документларның тулы исемлеге, | 1. Таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында гариза.<br>2. 3х4 см фотосурәт.<br>Таныклык алу өчен:<br>“Блокададагы Ленинградта яшәгән кешегә” билгесе белән бүләкләнгән гражданнар, өстәмә рәвештә, “Блокададагы Ленинградта яшәгән кешегә” билгесе таныклыгының күчермәсен тапшыра;<br>Бөек Ватан сугышы чорындагы фидакарь хезмәтләре өчен СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләнгән гражданнар, өстәмә рәвештә, Бөек Ватан сугышы чорындагы фидакарь хезмәтләре өчен СССР | № 69 Инструкциянең 2 п. 2.1 – 2.10 пунктчалары<br>№ 1122 Инструкциянең 8 п. |

| | | |
|---|---|---|
| мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны күрсәтү тәртибе | орденнары һәм медальләре белән бүләкләнү турындагы таныклыкның күчермәсен тапшыра;<br>1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәрге чорда тылда кимендә алты ай эшләгән гражданнар, өстәмә рәвештә, 1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәрге чорда тылда кимендә алты ай эшләгәнлекне раслаучы хезмәт кенәгәләренең, архив учреждениеләре һәм оешмалары белешмәләренең күчермәләрен тапшыра;<br>1.2.3 пунктта күрсәтелгән гражданнар, өстәмә рәвештә, РФ Хөкүмәтенең № 284 карары үз көченә кергәнгә кадәр бирелгән "Бөек Ватан сугышы ветераны" таныклыгының, яисә 1992 елның 1 гыйнварына кадәр расланган үрнәктәге таныклыгының күчермәсен тапшыра.<br>Таныклык күчермәсен алу өчен:<br>"Ленинград оборонасы өчен" медале белән бүләкләнгән, аларны пенсия белән тәэмин итү Россия Федерациясе Пенсия фонды органнары тарафыннан башкарыла торган затлар 1941 елның 8 сентябреннән 1944 елның 27 гыйнварына кадәрге блокада вакытында Ленинград шәһәре предприятеләрендә, учреждениеләре һәм оешмаларында эшләгәнлекне раслаучы архив учреждениеләре һәм оешмалары белешмәләренең һәм башка документларның, һәм "Ленинград оборонасы өчен" медале белән бүләкләнү турындагы таныклык күчермәләрен тапшырырга хокуклы;<br>бу Регламентның 1.2.2 пункты 2 пунктчасында күрсәтелгән гражданнар Бөек Ватан сугышы чорында һава һөҗүменә каршы оборона, һава һөҗүменә каршы җирле оборона объектларында, хәрәкәттәге фронтларның тыл янәшәсендәге чикләре тирәсендә, хәрәкәттәге флотларның операцияләр зоналарында, тимер һәм автомобиль юлларының фронт белән янәшә участокларында саклану корылмалары, хәрби-диңгез базалары, аэродромнар һәм башка төрле хәрби объектлар төзүдә эшләү фактын раслаучы документлар күчермәләрен тапшырырга хокуклы;<br>1941 – 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы чорындагы сугыш хәрәкәтләренә бәйле яралану, контузия яки имгәнү нәтиҗәсендә бала чакта инвалид калып, аларны пенсия белән тәэмин итү Россия Федерациясе Пенсия фонды органнары тарафыннан башкарыла торган затлар 1941 – 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы чорындагы сугыш хәрәкәтләренә бәйле яралану, контузия яки имгәнү нәтиҗәсендә бала чакта алган инвалидлыкның билгеләнгән группасы күрсәтелгән медицина- | |

| | | |
|---|---|---|
| | социаль экспертиза бюросы белешмәсе күчермәсен тапшырырга хокуклы;<br>бу Регламентның 1.2.2 пунктындагы 1 пунктчасының “а” – “з” пунктчаларында күрсәтелгән, аларны пенсия белән тәэмин итү Россия Федерациясе Пенсия фонды органнары тарафыннан башкарыла торган гражданнар аларны Бөек Ватан сугышында катнашучыларга кертү турында хәрби комиссариат белешмәсен яисә КПСС ҮК һәм СССР Министрлар Советының 27.02.1981 ел, № 220 карары нигезендә бирелгән Бөек Ватан сугышында катнашучы таныклыгын тапшырырга хокуклы.<br>Таныклык дубликатын алу өчен мөрәҗәгать иткән гражданнар өстәмә рәвештә тапшыра:<br>эчке эшләр органнарының югалган таныклыкның табылмаганлыгын раслаучы белешмәсен;<br>бозылган таныклыкны – әгәр элегрәк бирелгән таныклык яраксыз хәлгә килгән булса.<br>Документлар һәм белешмәләрне гариза бирүче тиешле оешмаларның үзләреннән, шул исәптән, андый мөмкинлек булганда, электрон рәвештә ала.<br>Документларның күчермәләре билгеләнгән тәртиптә расланмаган очракта, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Идарә (бүлек) белгече тарафыннан раслана.<br>Гариза бирүче, мөрәҗәгать иткәндә, шәхесен таныклаучы документ күрсәтә.<br>Дәүләт хезмәте алучыларның законлы вәкилләре (законнар нигезендә күздә тотылган очракларда) яки дәүләт хезмәте алучылар тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар, өстәмә рәвештә, дәүләт хезмәте алучының мәнфәгатьләреннән чыгып эш итүгә вәкаләтләрен раслаучы документлар күчермәләрен тапшыра.<br>Гаризаны почта аша җибәргәндә, гаризага кушып бирелә торган документлар күчермәләре Россия Федерациясе законына туры китереп расланган булырга тиеш. | |
| 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булып, мөрәҗәгать итүче | Бөек Ватан сугышы елларында тылда эшләү стажын билгеләү турында белешмә (Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасындагы бүлегеннән) (1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәрге чорда тылда кимендә алты ай эшләгән гражданнарга таныклык (таныклык дубликатын бирү өчен). | |

| | | |
|---|---|---|
| тапшыруга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны күрсәтү тәртибе; документларны үз карамагында тоткан дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма | Алучының категориясен һәм таныклыкны бирү көнен күрсәтеп, сугыш ветераны танклыгын бирү турында мәгълүматлар (Россия Федерациясе субъектлары законнарына туры китереп, таныклык бирергә вәкаләтле дәүләт органыннан) (таныклыкны югалткан очракта, анң дубликатын бирү өчен).<br>Гариза бирүче бу пунктта күрсәтелгән мәгълүматлар кергән докуменлартны тапшырырга хокуклы, шул исәптән, андый мөмкинлек булганда, электрон рәвештә.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсәтеп үтелгән мәгълүматларны эченә алган документларны тапшырмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигез булып тормый. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив-хокукый актларда күздә тотылган очракларда килештерергә тиешле (дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы хәл итә) дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Килештерү таләп ителми. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендәге документны тапшырмау;<br>2. Гариза бирүченең үзе яшәмәгән урында мөрәҗәгать итүе.<br>3. Документларда билгеләнгән тәртиптә расланмаган бетерүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм төзәтүләр булу. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки аннан баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торуга нигезләр билгеләнмәгән.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләр булып торалар:<br>бу Регламентның 1.3 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе;<br>документларда дәүләт хезмәте алучының бу Регламентның 1.2.1 һәм 1.2.2 пунктларында күрсәтелгән гражданнар категорияләренә керүен раслаучы мәгълүматлар булмау. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә. | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләргә түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Гариза бирүченең кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтү вакыты 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | № 601 РФ Президенты Указының 1 п. |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатен теркәү срогы | Гариза кергән көнне. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урынына, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат урнаштыруга карата таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү тиешле күрсәткеч язулар белән җиһазландырылган бүлмәләрдә башкарыла.<br>Дәүләт хезмәте алучыларны кабул итү бу максатлар өчен махсус бүлеп бирелгән һәм:<br>янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы;<br>документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар;<br>мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган урыннарда башкарыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең мөмкинлек һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, гариза бирүченең вазыйфаи | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып торалар:<br>документларны кабул итү һәм карап тикшерү сроклары үтәлү;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу срогы үтәлү;<br>дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан Регламент бозылу очракларының (нигезле шикаятьләрнең) булу-булмавы; | № 880 Тәртипнең 2.4 п. |

| | | |
|---|---|---|
| затлар белән аралашулары саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәктә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып | гариза бирүчеләрнең Идарә (бүлек) белгечләре белән аралашуы саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар биргәндә, турыдан-туры – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>әгәр гариза һәм документлар күчермәләре № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп электрон имза куелган (расланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелсә – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлек күрсәткечләре булып торалар:<br>бүлек биналарының җәмәгать транспорты йөри торган зонада урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләрнең булуы, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итеп алу өчен кирәкле санда бүлмәләрнең булуы;<br>мәгълүмат стендларында, “Интернет” челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>гаризаны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге.<br>Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, гариза бирүченең Идарә (бүлек) белгечләре белән бер тапкыр аралашуының дәвамлылыгы 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте (дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп) күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннары аша күрсәтелми.<br>Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турындагы мәгълүматны http://mtsz.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан алырга мөмкин. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Гариза һәм документлар күчермәләре Идарәгә (бүлеккә) № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә, гариза бирүченең электрон имзасы белән имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин. | № 63-ФЗ Федераль закон;<br>№ 210-ФЗ Федераль закон |

## 3. Административ процедуралар (гамәлләр) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннары аша үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы

3.1.1. Таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән электрон рәвештә) түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр төзү һәм җибәрү;

4) таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү;

5) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы бу Регламентка 4 нче кушымтада бирелә.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә

Гариза бирүче, дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Идарәгә (бүлеккә) шәхсән үзе, телефоннан, электрон почта аша яки хат белән мөрәҗәгать итә.

Идарә (бүлек) белгече, гариза бирүченең мөрәҗәгать итү ысулына бәйле рәвештә, шәхсән үзе, телефоннан, электрон почта аша һәм (яки) хат белән, мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге ягыннан, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Бу пункт билгели торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: консультация, гариза бирүчегә күрсәтелгән ярдәм, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.3. Гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче, Идарәгә (бүлеккә) таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында гариза һәм аңа кушып, бу Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар бирә.

Гариза һәм аңа кушып бирелүче документларның Россия Федерациясе законына турын китереп расланган күчермәләре (шәхесне таныклаучы документ күчермәсеннән гайре) почта аша җибәрелергә мөмкин.

Электрон почта аша электрон рәвештә җибәрелә торган гариза һәм документлар № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп имзалана.

Почта аша яки электрон рәвештә тапшырылган гариза һәм документлар гомуми тәртиптә карап тикшерелә.

3.3.2. Идарә (бүлек) белгече түбәндәгеләрне башкара:

законлы вәкил сыйфатында эш итүче гариза бирүченең яисә дәлүәт хезмәте алучы тарафыннан вәкаләт бирелгән затның вәкаләтләрен тикшерә;

кирәкле барлык документларның булуын һәм аларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен (документларда билгеләнгән тәртиптә расланмаган бетерүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм төзәтүләр булмауны) тикшерә.

Баш тартуга нигезләр булмаган очракта, Идарә (бүлек) белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризаны кабул итә һәм гражданнар мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында (2 нче кушымта) терки;

гариза бирүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүчегә документларын кабул итү датасы, бирелгән керү номеры турында билге белән расписка тапшыра; гаризаны почта, шул исәптән электрон почта аша җибәргәндә, документларын кабул итү датасы турында хәбәр итү язуын почта, шул исәптән электрон почта аша җибәрә.

Гаризаны теркәүдән һәм документларны кабул итүдән баш тартуга бу Регламентның 2.8 пункты белән күздә тотылган нигезләр булган очракта, Идарә (бүлек) белгече мөрәҗәгать итүчегә гаризаны теркәүдән һәм документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләр булу турында җиткерә һәм, баш тартуның сәбәпләрен язмача аңлатып, документларны аңа кире кайтара.

Бу пункт билгели торган процедуралар гариза һәм документлар кергән көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гаризаларны теркәү журналында теркәү язуы булдыру, расписка яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Идарә (бүлек) белгече, гариза бирүченең Бөек Ватан сугышы елларында тылда эшләү стажы булу турында мәгълүматлар бирүне сорап, Россия Федерациясе Пенсия фонды бүлегенә рәсми мөрәҗәгать җибәрә (1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәрге чорда тылда кимендә алты ай эшләгән гражданнарга таныклык (таныклык дубликатын) бирү өчен).

Идарәдә (бүлектә) бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән, таныклык (таныклык дубликатын) бирү турында карар кабул итү өчен кирәкле мәгълүматлар булганда, Идарә (бүлек) белгече рәсми мөрәҗәгать җибәрү бурычыннан азат ителә.

Бу пункт билгели торган процедура гариза һәм документлар теркәлгән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: мәгълүматлар бирү хакында рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.3.4. Идарә (бүлек) белгече, бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар һәм алынган документлар нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен бу Регламентның 2.9 пунктында күздә тотылган нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен бу Регламентның 2.9 пунктында күздә тотылган нигезләр булмаган очракта, Идарә (бүлек) белгече түбәндәгеләрне башкара:

таныклык (таныклык дубликаты) бланкын рәсмиләштерә;

гариза бирүченең "личное дело"сын рәсмиләштерә;

таныклык (таныклык дубликаты) бланкын, имза кую өчен, Идарә (бүлек) җитәкчесенә җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен бу Регламентның 2.9 пунктында күздә тотылган нигезләр булмаган очракта, Идарә (бүлек) белгече, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризада әйтелгән ысул белән (хат, телефон, смс-хәбәр, электрон почта), баш тартуның сәбәбен күрсәтеп, гариза бирүчегә таныклык (таныклык дубликатын) бирүдән баш тарту турында хәбәр итә.

Бу пункт билгели торган процедуралар рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар кергән көннән башлап 1 көн эчендә, ләкин гариза һәм документлар теркәлгән көннән башлап алты көннән дә соңламыйча үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: гариза бирүчегә таныклык (таныклык дубликатын) бирүдән баш тарту турында хәбәр итү, таныклыкның (таныклык дубликатының) рәсмиләштерелгән бланкы.

3.3.5. Документларны карап тикшергәннән соң, Идарә (бүлек) җитәкчесе таныклыкның (таныклык дубликатының) рәсмиләштерелгән бланкын имзалый һәм Идарә (бүлек) белгеченә җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедура таныклыкның (таныклык дубликатының) рәсмиләштерелгән бланкы имза куюга җибәрелгән моменттан башлап бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: таныклыкның (таныклык дубликатының) рәсмиләштерелгән, Идарә (бүлек) җитәкчесе тарафыннан имзаланган бланкы.

3.3.6. Идарә (бүлек) белгече гариза бирүчене таныклык (таныклык дубликатын) алырга килергә чакыра (хат, телефон, смс-хәбәр, электрон почта аша).

Бу пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчене таныклык (таныклык дубликатын) алырга килергә чакыру.

3.3.7. Идарә (бүлек) белгече:

таныклыклар бирү кенәгәсенә (3 нче кушымта) язып куя;

гариза бирүчегә таныклык (таныклык дубликатын) бирә.

Бу пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче килгән көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: таныклыклар бирү кенәгәсендәге язма, тапшырылган таныклык (таныклык дубликаты).

3.4. Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәк һәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннары аша күрсәтелми.

3.5. Техник хаталарны төзәтү

Таныклыкны (таныклык дубликатын) үзгәртеп рәсмиләштерү элегрәк бирелгән таныклыкта (таныклык дубликатында) җибәрелгән техник хаталарны (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хата яисә бүтән хата) бетерүгә бәйле рәвештә башкарыла.

Таныклыкны (таныклык дубликатын) үзгәртеп рәсмиләштерү техник хаталы таныклык (таныклык дубликаты) өстәлгән теркәлгән гариза (5 нче кушымта) нигезендә башкарыла.

3.5.1. Идарә (бүлек) белгече:

техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында (2 нче кушымта) терки;

таныклык (таныклык дубликаты) бланкын үзгәртеп рәсмиләштерә;

үзгәртеп рәсмиләштерелгән таныклык (таныклык дубликаты) бланкын, имза кую өчен, Идарә (бүлек) җитәкчесенә җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедуралар гариза теркәлгән моменттан башлап бер көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турындагы кабул ителгән, теркәлгән гариза, үзгәртеп рәсмиләштерелгән һәм имза кую өчен, Идарә (бүлек) җитәкчесенә җибәрелгән таныклык (таныклык дубликаты) бланкы.

3.5.2. Идарә (бүлек) җитәкчесе үзгәртеп рәсмиләштерелгән таныклык (таныклык дубликаты) бланкын имзалый һәм Үзәк бүлеге белгеченә җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедура таныклык (таныклык дубликаты) бланкы имза куюга җибәрелгән моменттан бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: имзаланган таныклык (таныклык дубликаты) бланкы.

3.5.3. Идарә (бүлек) белгече, гаризада күрсәтелгән ысул белән (хат, телефон, смс-хәбәр, электрон почта аша), гариза бирүчене үзгәртеп рәсмиләштерелгән таныклык (таныклык дубликатын) алырга килергә чакыра.

Бу пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчене үзгәртеп рәсмиләштерелгән таныклык (таныклык дубликатын) алырга килергә чакыру.

3.5.4. Идарә (бүлек) белгече:

таныклыклар бирү кенәгәсенә (3 нче кушымта) язып куя;

гариза бирүчегә үзгәртеп рәсмиләштерелгән таныклык (таныклык дубликатын) бирә.

Бу пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче килгән көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: таныклыклар бирү кенәгәсендәге язма, тапшырылган үзгәртеп рәсмиләштерелгән таныклык (таныклык дубликаты).

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итү тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген үтәүгә агымдагы контрольлек Идарә (бүлек) җитәкчесе тарафыннан Регламент нигезләмәләрен саклауга һәм үтәүгә тикшерүләр үткәрү юлы белән башкарыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итүне Министрлыкның вазыйфаи затлары башкара. Контрольлек итүче вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык турындагы нигезләмә һәм вазыйфаи инструкцияләр белән билгеләнә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфатына контрольлек дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы вазыйфаи затларның кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләрне карап тикшерүне, тикшерүләр үткәрүне, карарлар кабул итү һәм мөрәҗәгатькә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлүенә контрольлек формалары булып:

делопроизводствоны алып баруга;

документларны карап тикшерү нәтиҗәләренең законнар (бу Регламент) таләпләренә туры килүенә;

документларны кабул итү сроклары һәм тәртибе үтәлүгә;

дәүләт хезмәте күрсәткәндә нәтиҗәләрне бирү сроклары һәм тәртибе үтәлүгә тикшерүләр үткәрү тора.

Тикшерүләр уздыруның ешлыгы планлы (эш планнары нигезендә) һәм планнан тыш (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) була.

4.3. Гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу тикшерүләр нәтиҗәсендә ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гражданнар, аларның берләшмәләре, оешмалары тарафыннан контрольлек итү Идарә (бүлек) эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге ярдәмендә башкарыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата гариза бирүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерелү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар Идарәнең (бүлекнең) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр тәртиптә Идарә (бүлек) җитәкчесенә шикаять белдерүгә хокуклы.

Идарә (бүлек) җитәкчесе кабул иткән карарларга, кылган (кылмаган) гамәлләргә карата шикаятьләр Министрлыкка шуның белән шөгыльләнүче министр урынбасары яки министр исеменә бирелә.

Министр урынбасары (министр) кабул иткән карарларга, кылган (кылмаган)

гамәлләргә карата шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелергә мөмкин.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең рәсми мөрәҗәгатен теркәү срогы бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны гариза бирүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда;

дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи зат, хезмәткәрләре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

5.2. Шикаять язмача кәгазьдә яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://www.mtsz.tatar.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru) файдаланып җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карап тикшерү срогы – аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә, һәм дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, органның дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затының мөрәҗәгать итүчедән документларын кабул итеп алудан яисә җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына карата шикаять белдерү очрагында яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерү очрагында – аны теркәүгә алганнан соң биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

1) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның атамасы, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата шикаять белдерелә торган вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүченең – физик затның – фамилиясе, исеме, атасының исеме

(соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүматлар яисә атамасы, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре белән килешмәвенә дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре кушып бирелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә кушып бирелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаятькә шикаятьне тапшырган дәүләт хезмәте алучы имза сала.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча бу Регламентның 5.1 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи зат түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акчаны гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Бу пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм гариза бирүченең теләге буенча, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү буенча вәкаләт бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны, кичекмәстән, прокуратура органнарына җибәрә.

“Бөек Ватан сугышы ветераны” таныклыгын (таныклыкның дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының
______________________________
муниципаль районндагы (шәһәрдәге) Социаль яклау идарәсе (бүлеге)

# ГАРИЗА

Мин, ____________________________________________________________,
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы)
түбәндәге адрес буенча яшим:
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(гариза бирүченең адресы, телефоны, электрон почта адресы)

Шәхесне таныклаучы документ төре ___________________________________
______________________________________________________________________
(гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документ реквизитлары)

Түбәндәге документ нигезендә эш итәм: ______________________________
______________________________________________________________________
(гариза бирүченең дәүләт хезмәте алучы мәнфәгатьләреннән чыгып эш итүгә вәкаләтләрен раслаган документ реквизитлары)

“Бөек Ватан сугышы ветераны” таныклыгын (таныклыкның дубликатын) бирүегезне үтенәм ________________________________________________
(алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы)
______________________________________________________________________
(алучының яшәү урыны адресы, шәхесен таныклаучы документ реквизитлары)

Түбәндәге документларны кушып бирәм:

1. ____________________________________________________
2. ____________________________________________________
3. ____________________________________________________
4. ____________________________________________________

Таныклыкны югалту (бозу) шартларын аңлату (таныклык дубликатын биргәндә тутырыла):

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________.

2006 елның 27 июлендәге “Персональ мәгълүматлар турында” № 152-ФЗ Федераль законга нигезләнеп, бу Гаризада күрсәтелгән шәхси мәгълүматларымны җыюга, эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган эшкәртүгә, саклауга һәм мәгълүмат алмашу системасындагы өченче затларга тапшыруга ризалыгымны бирәм.

______________________________________________________________________________
(дәүләт хезмәте алучының, шулай ук гариза дәүләт хезмәте алучының мәнфәгатьләрен яклаучы зат тарафыннан бирелгән очракта, гариза бирүченең Ф.И.О. күрсәтелә)

_____________________________________________.
(гариза бирүченең имзасы)

Гариза бирүче:

_________________________________________ ___________ “__” _________ 20__ел
(дәүләт хезмәте алучының, гариза бирүченең яисә дәүләт хезмәте алучының мәнфәгатьләрен законда билгеләнгән тәртиптә расланган ышанычнамә нигезендә яклаучы затның Ф.И.О.) (имза)

Мәгълүматны, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) __________________________________________________ алырга риза.
(язмача, телефоннан, смс-хәбәр итеп, электрон почта белән)

“__” ________ 20__ ел Имза ______________

Гариза һәм документлар кабул ителде ___ 20__ел ______ ___________________
(белгеч имзасы, тулы имза)

______________________________________________________________________________

*Өзеп алу сызыгы*

Расписка-хәбәрнамә

Гариза бирүчене теркәү номеры

Документлар саны ___ берәмл. ___ биттә

Документларны кабул итте_________ ______ ____________ ________20____ел
(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)

"Бөек Ватан сугышы ветераны" таныклыгын (таныклыкның дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

Гаризаларны теркәү
**ЖУРНАЛЫ**

| Т-п № | Мөрәҗәгать итү көне | Мөрәҗәгатьнең номеры | Гражданинның ФИО | Адрес | Мөрәҗәгать итү сәбәпләре | Мөрәҗәгатьнең нәтиҗәләре | Сәбәпләре күрсәтелмәгән мөрәҗәгатьнең нәтиҗәләре |
|---|---|---|---|---|---|---|---|

"Бөек Ватан сугышы ветераны" таныклыгын (таныклыкның дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

## Таныклыклар бирү кенәгәсе

| Т-п № | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Өй адресы | Пенсия эше номеры (әгәр булса) | Таныклык-ның сериясе һәм номеры | Таныклык бирү көне | Таныклык-ны алучының имзасы | Искәр-мәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

"Бөек Ватан сугышы ветераны" таныклыгын (таныклыкның дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
5 нче кушымта

**Техник хатаны төзәтү турында**
**гариза**

Мин,______________________________________________________________________,
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)

түбәндәге адрес буенча яшим: ________________________________________________
__________________________________________________________________________
(индексын күрсәтеп, гариза бирүченең почта адресы, телефоны, электрон адресы)
__________________________________________________________________________
(гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документ атамасы, аның сериясе, номеры, бирү көне,
__________________________________________________________________________,
документны биргән орган атамасы)

"Бөек Ватан сугышы ветераны" таныклыгында (таныклыкның дубликатында)
__________________________________________________________________________
(таныклыкның реквизитлары, бирү көне)
җибәрелгән техник хатаны төзәтүне үтенәм.
Үзгәртеп рәсмиләштерелгән "Бөек Ватан сугышы ветераны" таныклыгын (таныклыкның дубликатын) бирү карары турында мәгълүматны ______________________________ алырга риза.
(язмача, электрон почта белән, смс-хәбәр рәвешендә)

"__" ________ 20__ ел ________________ ____________________________
(гариза бирүче имзасы) (тулы имза)

“Бөек Ватан сугышы ветераны” таныклыгын (таныклыкның дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
кушымта (белешмә)

**“Бөек Ватан сугышы ветераны” таныклыгын (таныклыкның дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында мәгълүматлар**

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органнары

| Территориаль орган атамасы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| Әгерҗе муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85551)<br>2-10-86<br>2-26-39 | 422230, Әгерҗе ш.,<br>К.Маркс ур., 8 й.<br>Agreez.Usz@tatar.ru |
| Азнакай муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85592)<br>7-25-10<br>7-14-25 | 423330, Азнакай ш.,<br>Болгар ур., 9 й.<br>Usz.Azn@tatar.ru |
| Аксубай муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84344)<br>2-73-68<br>2-82-75 | 423060, Аксубай ш.т.б.,<br>Ленин ур., 8 й.<br>Usz.Aksubaevo@tatar.ru |
| Актаныш муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85552)<br>3-11-46<br>3-12-81 | 423740, Актаныш ав.,<br>Юбилей ур., 45 й.<br>Usz.Aktanysh@tatar.ru |
| Алексеевск муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84341)<br>2-41-40<br>2-46-46 | 422900, Алексеевск ш.т.б.,<br>Казаков ур., 8 й.<br>Usz.Alekseevsk@tatar.ru |
| Әлки муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84346)<br>2-08-90<br>2-08-91 | 422870, Базарлы Матак ав.,<br>Ленин ур., 9 й.<br>Usz.Alkeevo@tatar.ru |
| Әлмәт муниципаль районындагы Социаль яклау идарәсе | (8553)<br>32-45-50 | 423452, Әлмәт ш.,<br>8 Март ур., 21а й.<br>Usz.Almet@tatar.ru |
| Апас муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84376)<br>2-11-84<br>2-10-81 | 422350, Апас ав.,<br>Шоссе ур., 5 й.<br>Usz.Apastovo@tatar.ru |
| Арча муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84366)<br>3-13-53<br>3-13-33 | 422000, Арча ш.,<br>Банк ур., 6в й.<br>Usz.Arsk@tatar.ru |
| Әтнә муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84369)<br>2-16-60<br>2-16-57 | 422750, Олы Әтнә ав.,<br>Октябрь ур., 9 й.<br>Usz.Atnya@tatar.ru |
| Баулы муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85569)<br>5-10-50<br>5-66-81 | 423930, Баулы ш.,<br>Җиңү мәйданы, 4 й.<br>usz.bavly@tatar.ru |
| Балтач муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84368)<br>2-44-78 | 422250, Балтач ав.,<br>Һ.Такташ ур., 3а й.<br>Usz.Baltasi@tatar.ru |

| Территориаль орган атамасы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| Бөгелмә муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85594)<br>4-20-05<br>4-26-64 | 423231, Бөгелмә ш.,<br>Совет ур., 56 й.<br>Usz.Bugulma@tatar.ru |
| Буа муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84374)<br>3-32-10<br>3-35-35<br>3-17-03<br>3-55-29 | 422430, Буа ш.,<br>Ленин ур., 52 й.<br>Usz.Buinsk@tatar.ru |
| Югары Ослан муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84379)<br>2-17-57<br>2-13-01 | 422570, Югары Ослан ав.,<br>Медгородок ур.<br>Usz.V-uslon@tatar.ru |
| Биектау муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84365)<br>2-32-43 | 422700, Биектау т/ю ст. б.,<br>Профсоюзлар ур., 1а й.<br>Usz.Vgora@tatar.ru |
| Чүпрәле муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84375)<br>2-38-07<br>2-31-52 | 422470, Иске Чүпрәле ав., Үзәк ур., 15 й.<br>Drozh.Usz@tatar.ru |
| Алабуга муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85557)<br>7-51-55<br>7-87-86 | 423600, Алабуга ш.,<br>Спас ур., 3 й.;<br>Usz.Elabuga@tatar.ru |
| Зәй муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85558)<br>7-10-64<br>3-43-59 | 423520, Зәй ш.,<br>Крупская ур, 6 й.<br>Usz.Zainsk@tatar.ru |
| Зеленодол муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84371)<br>5-58-80<br>5-79-90 | 420540, Зеленодол ш.,<br>Ленин ур., 25 й.<br>Usz.Zeldol@tatar.ru |
| Кайбыч муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84370)<br>2-14-07<br>2-11-13 | 422330, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й.<br>Usz.Kaybicy@tatar.ru |
| Кама Тамагы муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84377)<br>2-15-57<br>2-12-45 | 422820, Кама Тамагы ш.т.б.,<br>Карл Маркс ур., 2 й.<br>Usz.K-uste@tatar.ru |
| Кукмара муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84364)<br>2-84-76<br>2-64-65 | 422110, Кукмара ш.т.б.,<br>Ворошилов ур., 44 й.<br>Usz.Kukmor@tatar.ru |
| Лаеш муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84378)<br>2-47-31<br>2-49-70 | 422610, Лаеш ш.т.б., Беренче Май ур., 35 й.<br>Osz.Laishevo@tatar.ru |
| Лениногорск муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85595)<br>5-07-51<br>6-02-26 | 423250, Лениногорск ш.,<br>Горький ур., 21 й.<br>Usz.Leninogorsk@tatar.ru |
| Мамадыш муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85563)<br>3-12-36 | 422190, Мамадыш ш.,<br>Совет ур., 10 й.<br>Usz.Mamadysh@tatar.ru |
| Менделеев муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85549)<br>2-23-00 | 423650, Менделеев ш.,<br>Бурмистров ур., 7а й.<br>Usz.Mendeleev@tatar.ru |
| Минзәлә муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85555)<br>3-26-59<br>3-19-77 | 423700, Минзәлә ш.,<br>Ленин ур., 80 й.<br>Usz.Menzelinsk@tatar.ru |

| Территориаль орган атамасы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| | 3-14-52 | |
| Мөслим муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85556)<br>2-57-37 | 423970, Мөслим ав.,<br>Пушкин ур., 47 й.<br>Usz.Muslyumovo@tatar.ru |
| “Чаллы шәһәре” муниципаль берәмлегендәге Социаль яклау идарәсе | (8552)<br>34-48-48<br>58-71-52 | 423805, Чаллы ш.,<br>проспект Х.Туфана, д. 23<br>Usz.Chelny@tatar.ru |
| Түбән Кама муниципаль районындагы Социаль яклау идарәсе | (8555)<br>45-39-20<br>45-43-86<br>45-43-89 | 423570, Түбән Кама ш.,<br>Тынычлык пр., 60 й.<br>usznizhnekamck@tatar.ru |
| Яңа Чишмә муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84348)<br>2-20-15 | 423190, Яңа Чишмә ав., Совет ур., 80 й.<br>Usz.Novoshesh@tatar.ru |
| Нурлат муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84345)<br>2-06-62<br>2-06-55<br>2-39-88 | 423042, Нурлат ш.,<br>Мәктәп ур., 8 й.<br>Usz.Nurlat@tatar.ru |
| Питрәч муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84367)<br>3-06-68<br>3-06-72 | 422770, Питрәч ав.,<br>Совет ур., 20 й.<br>Usz.Pitriash@tatar.ru |
| Балык Бистәсе муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84361)<br>2-11-57<br>2-39-62 | 422650, Балык Бистәсе ав., Завод ур., 6а й.<br>Usz.R-sloboda@tatar.ru |
| Саба муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84362)<br>2-34-37 | 422060, Байлар Сабасы ав.,<br>Тукай ур., 87 й.<br>Usz.Saby@tatar.ru |
| Сарман муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85559)<br>2-45-72<br>2-49-87 | 423350, Сарман ав.,<br>Куйбышев ур., 36 й.<br>Usz.Sarmanovo@tatar.ru |
| Спас муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84347)<br>3-08-81<br>3-00-00<br>3-08-98 | 422864, Болгар ш.,<br>Хирург Шеронов ур., 13 й.<br>Usz.Bolgar@tatar.ru |
| Тәтеш муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84373)<br>2-62-31 | 422370, Тәтеш ш.,<br>Ленин ур., 114 й.<br>Usz.Tetyushi@tatar.ru |
| Тукай муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (8552)<br>70-00-57 | 423807, Чаллы ш., М.Җәлил проспекты, 46 й.<br>Usz.Tukaev@tatar.ru |
| Теләче муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84360)<br>2-13-41 | 422080, Теләче ав.,<br>Большая Нагорная ур., 5 й.<br>Usz.Tulachi@tatar.ru |
| Чирмешән муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84396)<br>2-57-05<br>2-50-94 | 423100, Чирмешән ав.,<br>Гагарин ур, 7 й.<br>Usz.Cheremshan@tatar.ru |
| Чистай муниципаль районындагы Социаль | (84342)<br>5-55-73 | 422980, Чистай ш.,<br>Урицкий ур., 45 й. |

| Территориаль орган атамасы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| яклау бүлеге | 5-11-50 | Usz.Chistopol@tatar.ru |
| Ютазы муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85593)<br>2-21-43<br>2-82-91<br>2-84-41 | 423950, Урыссу ш.т.б.,<br>Пушкин ур., 105/1 й.<br>Usz.Utazy@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Авиатөзелеш районындагы Социаль яклау бүлеге | 571-58-00 | 420036, Казан ш.,<br>Тимирязев ур., 8 й.<br>Usz.Avia@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Вахитов районындагы Социаль яклау бүлеге | 238-10-55 | 420197, Казан ш.,<br>Вишневский ур., 10 й.<br>Usz.Vahit@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Киров районындагы Социаль яклау бүлеге | 554-47-80 | 420102, Казан ш.,<br>Галимҗан Баруди ур., 5 й.;<br>Usz. Kirov@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Мәскәү районындагы Социаль яклау бүлеге | 544-89-94 | 420095, Казан ш.,<br>Блюхер ур., 81а й.<br>Usz.Moskov@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Яңа Савин районындагы Социаль яклау бүлеге | 523-75-82 | 420124, Казан ш.,<br>Хөсәен Ямашев проспекты, 37 й.<br>Usz.Novosavin@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Идел буе районындагы Социаль яклау бүлеге | 224-04-20 | 420110, Казан ш.,<br>Рихард Зорге ур., 39 й.<br>Usz.Priv@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Совет районындагы Социаль яклау бүлеге | 273-18-06 | 420073, Казан ш.,<br>Гадел Кутуй ур., 33 й.;<br>Usz.SovOR@tatar.ru |

## 2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-02 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-07 | mtsz@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чаралары методологиясе бүлеге начальнигы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Күрсәтелүче социаль ярдәм чараларының функциональ аудиты бүлеге начальнигы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru |

## 3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Социаль үсеш идарәсе начальнигы | 264-77-29 | pisma@tatar.ru |

“Бөек Ватан сугышы ветераны” таныклыгын
(таныклыкның дубликатын) бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
4 нче кушымта

## “Бөек Ватан сугышы ветераны” таныклыгын (таныклыкның дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәткәндә, гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы

